КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 4 май г.Казань № 305

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты турында» 2019 ел, 2 декабрь, 1094 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты турында» 2019 ел, 2 декабрь, 1094 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 июнь, 545 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» һәм «е» пунктчаларын өстәргә:

«д) әлеге Нигезләмәнең 5 һәм 13 пунктларындагы таләпләрне үтәмәү;

е) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә гражданны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар исемлегендә һәм әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта нигезендә предприятие, учреждение, оешма коллективын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хаты белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар исемлегендә күрсәтелгән документларның берсе булмау.»;

Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 6 пунктында «уку йорты исеме» сүзләрен «югары белем бирүче мәгариф оешмасы исеме» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәгә 2 нче кушымтада:

6 пунктта:

беренче абзацта «, шулай ук оешмалар коллективларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«**» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«** Әлеге исемлекнең «а» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган белешмә кәгазьләре ирекле рәвештә тутырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Оешманың һәм гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә кәгазьләре***.

---

***Белешмә кәгазьләре тиешле салым органнары тарафыннан билгеләнгән форма буенча бирелә.»;

Нигезләмәгә 3 нче кушымтада:

икенче абзацта «уку йорты исеме» сүзләрен «югары белем бирүче мәгариф оешмасы исеме» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «һәркем файдалана алырлык сыйфатта» сүзләрен төшереп калдырырга;

Нигезләмәгә 5 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 7 нче пункт өстәргә:

«7. Юбилей даталарына бәйле рәвештә, Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында үтенечнамәләр булдырылганда – архив белешмә кәгазе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин